**Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Мамык авыл җирлеге Мамык авылы торак пунктында гражданнар җыены**

**КАРАРЫ**

«01» ноябрь 2025 ел № 4

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 45 маддәсе нигезендә, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Мамык авыл җирлеге Мамык авылы торак пункты гражданнары җыены

КАРАР ИТТЕ**:**

1. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Мамык авыл җирлеге Мамык авылы территориясендә яшәүче һәр балигъ булган кешедән, 1 гр инвалидларыннан, балачак инвалидларыннан, Бөек Ватан сугышы ветераннарының тол хатыннары, махсус хәрби операциядә катнашучылар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан, көндезге бүлектә укучы студентлардан, теркәлгән, ләкин яшәмәүчеләрдән кала, 2026 елда 1000 сум күләмендә үзара салым кертү һәм җыелган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Ворошилов ур.);

- ремонт, коймалар кору, традицион күмү урыннарын төзекләндерү;

- су белән тәэмин итү һәм ташу системаларын, су җыю манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортировкалауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итә торган башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау;

- авыл җирлеге территориясен төзекләндерү (Куйбышев һәм Приозерная урамнарында авария хәлендәге иске агачларны кисү; Ворошилов, Куйбышев урамнарындагы җәяүлеләр басмасын ремонтлау).

Халык җыенында рәислек итүче: В.В. Рыжков

Мамык авыл җирлеге башлыгы В.В. Рыжков